РАСЛЫЙМ
МАУ «Шатлык » яшьләр үзәге»
Директоры Г. Х. Ковальчук ________
«____» ______________________ 2018 г.

# ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МАУ «ШАТЛЫК» ЯШЬЛӘР ҮЗӘГЕ» ИҖАТ БЕРЛӘШМӘСЕНӘ КАБУЛ ИТҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Кагыйдәләр Яр Чаллы шәһәре Муниципаль автоном учреждениесе «Шатлык» яшьләр үзәге Уставы нигезендә эшләнә.

1.2. МАУ «Шатлык» яшьләр үзәге Уставы нигезендә түгәрәкләргә, студиягә, клубларга йөрүчеләрдән баш тарту , кеше саны артык булу сәбәпле генә булырга мөмкин.

1.3. МАУ «Шатлык» яшьләр үзәгендә базасында түгәрәкләр, студияләр, шулай ук башка хезмәтләр бушлай.

1.4 Коллектив җитәкчесенең иҗат берләшмәсенә кабул итүнең үз кагыйдәләре була.

## II. КОЛЛЕКТИВКА КАБУЛ ИТҮ ШАРТЛАРЫ

2.1. МАУ «Шатлык» яшьләр үзәгенә, Яр Чаллы шәһәре халкы кагыйдәләр белән танышканнан соң түгәрәкләргә һәм студияләргә кабул ителә. Ата-аналардан баланы кабул итү турында гаризасы нигезендә балалар түгәрәккә кабул ителә. Өлкәннәр шәхси гариза нигезендә кабул ителәләр.

2.2. Түгәрәкләргә һәм студиягә кабул иткәндә тыңлау, әңгәмә(кирәк булганда)үткәрелә.

2.3. Сәнгать җитәкчесе расписание нигезендә дәресләгә, түгәрәкләргә, студияләрга һәм коллективларга кирәк булган очракта үзгәрешләр кертергә мөмкин. Коллектив җыю чоры агымдагы елның 1 сентябрьдән 15 сентябрьга кадәр үткәрелә.

2.4. Түләүле дәресләр, студияләргә нигездә ай саен түләү, агымдагы айның10 на кадәр башкарыла.

2.5. Бала авырган очракта яки булмаганда медицина белешмәсе кирәк була. Бала дәрестә булмаган очракта, түләү дә, яңадан исәпләү дә башкарыла.

## III . ДӘРЕСЛӘР КАГЫЙДӘЛӘРЕ БЕЛӘН ТАНЫШУ

3.1. Расписание нигезендә катнашучылар дәресләргә йөрергә тиеш.

3.2. Катнашучылар һәм аларны озата баручы затлар дәресләр башланырга 15-20 минутка иртә килә.

3.3. Катнашучылар шөгыльләргә килә алмау сәбәпле, җитәкчене алдан ук кисәтеп куярга тиеш. Башкалар өчен куркыныч, йогышлы авырулар вакытында дәресләр йөрү катгый тыела.

3.4. Катнашучылар шөгыльләрдә җитәкче биремнәрен һәм дисциплинаны катгый үтәргә тиешләр.

3.5 Җитәкче рөхсәте белән баланың эти-әнисе дәресләргә керергә мөмкин.

3.6. МАУ «Шатлык» яшьләр үзәге ел дәвамында үткәрелүче планлы чаралар: бәйрәмнәр, фестивальләр, бәйгеләр, отчет концертлары һ. б. Әлеге чараларда катнашу шулай ук иҗат процессының бер өлеше булып тора, катнашучылар өчен мәҗбүри санала.

3.7. МАУ «Шатлык» яшьләр үзәге балалар өчен чараларда, (генераль репетицияләр, концертлар, бәйгеләр, бәйрәмнәр һ. б.) катнашучылар өчен клуб булдыру иҗат процессынның бер өлеше булып тора һәм мәҗбүри санала.

3.8. Шөгыльләнү өчен кирәк-яраклар: уку әсбаплары, канцелярия товарлары, махсус кием, аяк киеме һәм башка кирәкле әйберләр ата-аналар хисабына алына.

3.9. МАУ«Шатлык» яшьләр үзәгендә мөлкәткә, уку пособиясе, музыкаль инструментларга, инвентарьга һ. б катнашучылар саклык белән карарга тиеш. Укучылар МАУ«Шатлык» яшьләр үзәгендә милкенә зыян китергән очракта, эти-әниләр зыян өчен түләргә бурычлы.

3.10. Залларда, холлда, сыйныфларда һәм бәдрәф бүлмәләрендә тәртип һәм чисталык үтәргә бурычлы.

3.11. МАУ «Шатлык» яшьләр үзәге администрациясе
— гардеробка тапшырылмаган чит әйберләр өчен,
— фойеда һәм раздевалкада караучысыз калган шәхси әйберләр өчен җаваплылык тотмый.

3.12. Катнашучылар бурычы:
— эчке тәртип кагыйдәләрен үтәргә;
— гариза нигезендә кабул ителгән шартларны катгый үтәргә;
— берләшмә җитәкчеләреләре тарафыннан билгеләнгән барлык биремнәр даими рәвештә үтәргә, дәресләргә йөрергә.

3.13. Коллектив җитәкчеләре:
— МАУ «Шатлык» яшьләр үзәгендә дәресләр үткәрергә һәм мәдәни-агарту чаралары нигезендә расланган планнары һәм шәхси планнары белән уртаклаша.
— Дәресләрне көннәре һәм сәгатьләре билгеләнгән расписание буенча үткәрергә.
—Массакүләм чаралар үткәрергә әзерләгәндә, өстәмә дәресләр һәм репетиция көннәрендә һәм сәгатьләрендә, администрациясе белән килешеп эшләнелә.
—Коллективларда һәм түгәрәкләрдә катнашучы тупас, дисциплинаны һәм кагыйдәләрне бозган очракта коллективтан чыгарыла .